Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы Советы
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» 2024 елның 27 июнендәге 253 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен арттыру турында» 2024 елның 21 сентябрендәге 820 номерлы карарына ярашлы рәвештә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының 2024 елның 27 июнендәге 253 номерлы карарының 1 өлешендәге 3 абзацында түбәндәгеләрне бәян итәргә: «җитәкчеләрнең вазыйфаи окладлары күләмнәре, Чирмешән муниципаль районының аерым оешмалары белгечләре һәм хезмәткәрләре Татарстан Республикасы Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган муниципаль берәмлекләрдәге бюджет өлкәсенең аерым оешмасы структур бүлекчәсе җитәкчесе секретаренең вазыйфаи окладь күләменә карата 13 990 сум тәшкил итә»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы башлыгы урынбасарына, Совет рәисе урынбасарына йөкләргә.

4. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Чирмешән муниципаль районы Башлыгы,
Татарстан Республикасы Чирмешән
муниципаль районы Советы рәисе Р.Т. Айбатов